ГЛАВА
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2019 г. Агрыз № 29

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башлыгының 2016 елның 22 сентябрендәге 104нче санлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советына мөрәҗәгать иткәндә шәхси мәгълүматларны эшкәртү Сәясәтенә үзгәрешләр кертү турында

"Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 ел, 27 июль ФЗ-152нче санлы Федераль законның таләпләрен исәпкә алып карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башлыгының 2016 елның 22 сентябрендә 104нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советына мөрәҗәгать иткәндә шәхси мәгълүматларны эшкәртү Сәясәтенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

"2.4. Мәгълүмати тәэмин итү максатларында Әгерҗе муниципаль район Советында хезмәткәрләрнең һәркем өчен ачык шәхси мәгълүмат чыганаклары, шул исәптән белешмәлекләр һәм адреслы китаплар төзелә ала. Һәркем өчен ачык мәгълүмат чыганакларына хезмәткәрнең язма ризалыгы белән аның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы һәм урыны, адресы, абонент номеры, һөнәре турында мәгълүмат һәм башка шәхси мәгълүматлар кертелә ала.

Хезмәткәр турындагы мәгълүматлар хезмәткәр таләбе яки суд карары яисә башка вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан һәркем өчен ачык булган шәхси мәгълүмат чыганакларыннан теләсә кайсы вакытта төшереп калдырылырга тиеш.

2.6 пунктның 4 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

"шәхси мәгълүматларны эшкәртү дәүләт социаль ярдәме, хезмәт законнары, Россия Федерациясе пенсия законнары нигезендә башкарыла".

2. Әгерҗе муниципаль районы Советы муниципаль хезмәткәрләрен әлеге Карар белән таныштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Әгерҗе муниципаль районы сайтының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составына http://agryz.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.Ә.Закировага йөкләргә.

**В.В. МАКАРОВ**